РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» март 2020 ел г. Альметьевск № 18

Әлмәт муниципаль районы
башлыгының кайбер карарларын
гамәлдән чыгару турында

Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча, муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2020 елның 10 февралендәге 93-пр протесты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районы башлыгы карарларын гамәлдән чыгарырга:

- «Әлмәт муниципаль районында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2016 елның 26 маендагы 44 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә эвакуация пунктларын булдыру турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 126 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контроль челтәре турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 08 февралендәге 26 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасының яклау корылмаларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2017 елның 29 июнендәге 127 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы халкына хәбәр итү системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 161 номерлы;

«Әлмәт муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзер килеш тоту турында» 2017 елның 28 декабрендәге 198 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы идарәсенең шәһәр запас пунктын «Таттелеком» гавами акционер җәмгыятенең Әлмәт зональ элемтә үзәгендә гражданнар оборонасын саклау корылмасында урнаштыру турында» 2019 елның 26 апрелендәге 46 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районының кабул итү эвакуация комиссиясе турында нигезләмәне раслау һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә кабул итү эвакуация пунктларын булдыру турында» 2016 елның 28 ноябрендәге

Зак. № 304

126 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 маендагы 52 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзер хәлдә тоту турында» 2017 елның 28 декабрендәге 198 номерлы Әлмәт муниципаль районы башлыгының карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 22 маендагы 54 номерлы карары.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Муниципаль район
Башлыгы Т.Д. Нагуманов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ